Татарстан Республикасы
Кукмара муниципаль районы
Янил авыл җирлеге Советы

КАРАР

28.01. 2022 ел № 1

Янил авыл җирлеге Советының 2014 елның 30 январе 3 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Янил авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 33 статьясы, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Янил авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Янил авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. Янил авыл җирлеге Советының 2014 елның 30 январе 3 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Янил авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару Кагыйдәләренә, 18.1 статьясын түбәндәге нигездә бәян итеп, (Янил авыл җирлеге Советының 2016 елның 16 декабрендәге 39 номерлы, 2018 елның 21 июнендәге 20 номерлы, 2019 елның 20 февралендәге 3 номерлы, 2019 елның 29 августындагы 19 номерлы, 2021 елның 9 июнендәге 11 номерлы карары, 2021 елның 23 ноябрендәге 26 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып), үзгәрешләр кертергә:

«18. 1. Җир кишәрлекләренең чик күләме:

«Шәхси торак төзелеше», «шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен» рөхсәт ителгән файдалану төре белән җир кишәрлекләренең минималь күләме – 1 000 кв. м.

«Шәхси торак төзелеше» рөхсәт ителгән файдалану төре белән җир кишәрлекләренең максималь күләме– 2500 кв.м, «шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен» – 5000 кв.м.»

2. Әлеге карарны махсус мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

Җирлек башлыгы: И.Х. Корбанов

СОВЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ ЯНИЛЬСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ КУКМОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ★ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЯНИЛ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
ОГРН 1021607753310
ИНН 1623001893